| МИНИСТЕРСТВО ПО ДЕЛАМ ГРАЖДАНСКОЙ ОБОРОНЫ И ЧРЕЗВЫЧАЙНЫМ СИТУАЦИЯМ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ГРАЖДАННАР ОБОРОНАСЫ ЭШЛӘРЕ ҺӘМ ГАДӘТТӘН ТЫШ ХӘЛЛӘР МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|
| **ПРИКАЗ** | г. Казань | **БОЕРЫК** |
| 09.04.2026 | | № 79 |

**Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 09.01.2014 № 6 «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» боерыгына үзгәрешләр кертү турында**

2008 ел 25 нче декабрь № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы тору турында», 2012 ел 3 нче декабрь № 230-ФЗ «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законнарга һәм Татарстан Республикасының 2003 ел 12 нче гыйнвар № 3-ЗРТ «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Законына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгының 09.01.2014 № 6 «Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр Министрлыгында биләгәндә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт

граждан хезмәте вазыйфалары Исемлеген раслау турында» боерыгына (05.05.2014 № 205, 14.12.2015 № 572, 23.05.2016 № 215, 09.04.2019 № 136, 25.06.2020 № 209, 04.08.2021 № 256, 17.11.2021 № 388, 13.10.2022 № 300, 27.10.2022 № 310, 27.12.2023 № 365, 05.03.2024 № 72 Татарстан Республикасы ГТХМ боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) алдагы үзгәрешләрне кертергә:

2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Исемлеккә кертелгән Татарстан Республикасы ГТХМ дәүләт граждан хезмәте вазыйфасын биләүче Граждан яллаучы вәкиленә билгеләнгән срокларда, 2008 ел 25 нче декабрь № 273-ФЗ «Коррупциягә каршы тору турында» Федераль законда билгеләнгән очракларда, керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне, шулай ук 2012 ел 3 нче декабрь № 230-ФЗ «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» Федераль законда каралган чыгымнары турында белешмәләрне тапшырырга тиеш».

2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасы ГТХМ аппаратының министр урынбасарларына, структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә.

Министр вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А. Н. Орлов